ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИАЛЬ РАЙОНЫ
КЫШЛАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

СОВЕТ КШКЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422008 Республика Татарстан Атнинский район с. Кшклово. Тел. 3-43-45

# КАРАР

«09» ноябрь 2019 ел

№ 3

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль
районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау
торак пунктында гражданнарның үзара салым
акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 23 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә: торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә: Совет урамы 4 йорттан 42 йортка кадәр, Тукай урамы 1 йорттан 37 йортка кадәр.
2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 23 ноябрендә 18.00 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә: торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә: Татарстан урамы 1 йорттан 43 йортка кадәр, Чапай урамы 2 йорттан 32 йортка кадәр.
3. Билгеләргә:
   - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Башкарма комитеты;
   - гражданнар җыенының беренче этабын уздыру вакыты – 23 ноябрь 2019 ел 13.00 сәг. тән 14.00 сәг. кадәр;
   - гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты – 23 ноябрь 2019 ел 18.00 сәг. тән 19.00 сәг. кадәр;
   - гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын уздыру урыны – Кышлау авылы, Татарстан ур., 7 йорт, Кышлау мәдәният йорты залы;

4.Татарстан республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:
   - 2019 елның 12 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Кышлау авылы, Татарстан урамы, 7 йорт;

- сайлау хокукына ия булган Кышлау торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Кышлау торак пункты халкына гражданнар җыены турында мәгълүматны мәгълүмати стендлар аша һәм башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

5.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәьәләне расларга:

Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Кышлау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән, тавыш бирү хокукына ия булган, һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- Кышлау авылы Чапаев урамына 500 метр арадан чишмә суын китерү;
- торбалар сатып алу һәм салу, насос сатып алу.
2) җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
- Кышлау авылы территориясен чистарту.

"РИЗА" "КАРШЫ"

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында "Интернет" мәълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Кышлау авылы, Татарстан ур., 7 йорт, Кышлау авыл җирлеге Башкарма комитеты мәгълүмат стендында урнаштырырга.
7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
8. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Кышлау авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Шакирова